**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.04.2018 Балык Бистәсе штп. № 72пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге хакында» 2014 елның 9 сентябрендәге 161пи номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы, «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында "2018 елның 19 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законнары Татарстан Республикасы Законнары Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында» 2014 елның 9 сентябрендәге 161пи номерлы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 15.07.2015 №195пи, 17.08.2016 ел, №133пи, 18.10.2017 ел, №226пи карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1.) 1пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.Татарстан Республикасы административ хокук бозулар турындагы Кодексының 2.1 статьясында (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы, предприятие,

учреждение, башка оешма  үз исеме һәм элмә тактага урнаштырылырга тиешле бүтән мәгълүмат күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуларга карата), 2.6, 2.8, 2.14, 3.2 - 3.8, 3.10 статьяларында (гражданнарга карата), 3.11, 3.14-3.17, 4.4, 5.1, 5.2, 5.6 статьяларында каралган (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль йөк ташуларга карата) административ хокук бозулар турында үз компетенцияләре чикләрендә беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләргә.”;

1.2) карарга кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2.Бу карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә дип билгеләргә.

3.Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 9 сентябрендәге 161пи номерлы карарына кушымта (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 17 апрелендәге 72пи номерлы карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы административ хокук бозулар турындагы Кодексының 2.1 статьясында (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы, предприятие, учреждение, башка оешма үз исеме һәм элмә тактага урнаштырылырга тиешле бүтән мәгълүмат күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуларга карата), 2.6, 2.8, 2.14, 3.2 - 3.8, 3.10 статьяларында (гражданнарга карата), административ хокук бозулар турында үз компетенцияләре чикләрендә беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге

I. Татарстан Республикасы административ хокук бозулар турындагы Кодексының 2.1 статьясында (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы, предприятие, учреждение, башка оешма үз исеме һәм элмә тактага урнаштырылырга тиешле бүтән мәгълүмат күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуларга карата) каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар

- «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе башлыгы урынбасары (укыту-методик эш буенча);
- «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесенең милли мәгариф буенча методисты;

II. Татарстан Республикасы административ хокук бозулар турындагы Кодексының 2.6, 2.8, 2.14, 3.2, 3.16, 5.1, 5.2, 5.6 статьяларында каралган (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль йөк ташуларга карата) каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар

- Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы;
- Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы урынбасары.

III. Татарстан Республикасы административ хокук бозулар турындагы Кодексының 2.6, 3.3-3.7, 3.10 статьяларында (гражданнарга карата), каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле

вазыйфаи затлар

- Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак–коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы;
- Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак–коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы урынбасары;

## IV. Татарстан Республикасы административ хокук бозулар турындагы Кодексының 3.8, 3.11, 3.14, 3.15 статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар

-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты тәртип саклау җәмәгать пунктлары эшчәнлеген тәэмин итү секторының әйдәп баручы белгече (балигъ булмаганнар арасында гаилә иминлеген һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча инспектор).

## V. Татарстан Республикасы административ хокук бозулар турындагы Кодексының 3.17 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар

- Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак–коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы;
- Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак–коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы урынбасары;
-Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы урынбасары.